**ГЛАВА ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

2023 елның 11 мае    32-ПГ номер

# КАРАР

**2022 елда Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы халкының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставының 16 статьясы нигезендә 2022 елда Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында район Советы Карары проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында КАРАР БИРӘМ**:**

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджеты проекты буенча Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Лебедева ур., 32 йорт -район мәдәният йорты бинасында 2023 елның 25 маена 16.00 сәгатькә гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. 2022 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджеты проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР, Лаеш муниципаль районы, «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Беренче Май урамы, 39 йорт, 17 каб. яки факс буенча- 884378 2-51-59, 2023 елның 25 маена кадәр.

3. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча Оештыру комитетының түбәндәге составын расларга:

1) Е.Н.Галиева – районның финанс-бюджет палатасы рәисе, Оештыру комитеты рәисе;

2) О.А.Грачева – районның финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары;

3) Р.Р.Агмалов – район Советы Аппаратының Оештыру бүлеге начальнигы, оештыру комитеты секретаре;

4) Н.С.Гыйлаҗетдинова – Комлы Ковал авыл җирлеге башлыгы, район Советы депутаты;

5) Т.Н.Купчихина – «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге башкарма секретаре.

4. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советы Аппараты җитәкчесе Р.Т.Гарифуллинга йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы**    **И.Ф. Зарипов**